| ГЛАВА<br>Девятернинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Девәтернә авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2020 Девәтернә авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2020 елның 16 ноябрендә 14 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2020 елның 16 ноябрендә 15 сәг 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Нарат торак пунктының Айтуганов урамында яшәүчеләр.

-2 этап: Нарат торак пунктының Мәйдан, Үзәк урамнарында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым

чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдаланугa ризамы:

1. Тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, өстәмә җиһазлар (төягеч, чапкыч, тагылма) сатып алу.

2. Нарат торак пункты урамнарын яктыртуны карап тоту (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны сатып алу, урнаштыру һәм алмаштыру) өлешендә гамәлләр.

3. Нарат торак пунктын су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм материаллар сатып алу, ремонтлау, хезмәт күрсәтү.

4. Нарат торак пункты урамнарын кардан чистарту (ГСМ, майлар сатып алу).

5. Янгын автомашинасын карап тоту, ремонтлау, янгын автомашинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.

6. Нарат торак пунктында хуҗасыз йортларны карап тоту, фасадларның тышкы кыяфәтен төзекләндерү (агач материаллар, торбалар, профильләр алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Нарат авылында Үзәк ур., 22 йорт адресы буенча авыл клубында уздырырга.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Ф.М. ЙОСЫПОВ

Совет Девятернинского сельского поселения
Девәтернә авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002846